

Халыкара олкәннәр ае дәвам итә. Тормышыбызны ямьләп, акыллы кинәшләрен биреп яшәvче, сабыр, зирәк, изге жанлы олы яшьтәге ак яулыклы әбиләребезне, апаларыбызны, матур тvбәтәйле бабайларыбыз-абыйларыбызны бәйрәмнәре белән ихлас йорәктән тәбрик итәбез һәм озын-озак бәхетле гомерләр, кvтәренке кәеф, балалар-оныклар куанычы теләп калабыз. Сезнен барыгызга да гомерегезнен һәр конен сәламәтлек, жан тынычлыгы һәм якыннарыгызнын кvнел жылысын тоеп vткәрергә язсын!

Мордовия Республикасында, 2025 елнын 1 октябренә китерелгән саннар буенча, 790 197 кеше яши, шул исәптән 30 яшьтән 60 яшькә кадәрге олкәннәр - 339 982 кеше, 60 яшьтән олкәнрәкләр - 172 263 кеше, ә республиканын озак гомерле



кешеләре - 60 яшьтән олкәнрәкләр - 172 263 кеше. Мордовиядә 80 яшьтән олкәнрәкләр - 11 063 кеше. Барлыгы Мордовиядә 212 меннән артык пенсионер яши.
Социаль фонднын Мордовия буенча бvлеге Халыкара олкәннәр конендә катнашы

булганнарны чын күнелдән бәйрәм белән котлый һәм комеш яшьтәге гражданнарга фонд линиясе буенча торле ярдәм чаралары каралуын искәртә. Мәсәлән, 80 яшькә житкән картлык буенча иминият (страховой) пенсиясен алучыларга СФР бүлеге пенсиягә билгеләнгән түләүләрне икеләтә арттыра. 2025 елда картлык буенча иминият пенсиясе алучы республика гражданнары очен теркәлгән түләү күләме 8 907 сум 70 тиен тәшкил итә, ә 80 яшьтән олкәнрәкләр очен - 17 815 сум 40 тиен. Югары теркәлгән түләүгә бары тик картлык буенча иминият пенсиясен алучылар гына хокуклы. Түләү



автомат рәвештә янадан исәпләнә, олкәннәргә бернинди гариза бирергә кирәкми. Теркәлгән түләү алучыга 80 яшькә житкәннән сон киләсе айга ук юбилей коненнән остәмә түләү белән исәпләнәчәк.Бүгенге кондә Мордовиядә 22 312 пенсионер пенсиягә югары теркәлгән түләү ала, шуларнын 17 944се - хатын-кызлар, 4 368се - ир-атлар. Республикада яшәүче 3 012 кеше инде 90 еллыгын билгеләп үтте (ягъни Ботендонья сәламәтлек саклау оешмасы классификациясе буенча озак яшәүчеләр булып санала), ә аларнын 57се гасыр чиген узган. Тобәкнен ин олкән яшьтәге хатын-кызы Большие Березники районында яши: берничә кон элек ана 103 яшь тулган. Ин олкән ир-ат - Саранск шәһәре кешесе. Ноябрьдә ул шулай ук үзенен 103 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк. Озак яшәүчеләргә ин бай Мордовия башкаласы булып чыкты: Саранскта 90 яшьтән олкәнрәк 1 031 пенсионер яши.
Шулай ук 2025 елдан башлап Мордовия буенча СФР бүлеге 80 яшькә житкән республика халкына пенсиягә остәмә буларак остәмә түләү (2025 елда - аена 1 314 сум) рәсмиләштерә. Элек бу түләүне эшләмәүчеләр олкән яшьтәге гражданнарны карау сәбәпле рәсмиләштергәннәр.

Чәчләренә чал кергән олыларыбызны, ай буе торле-торле юллар белән күнелләрен берәр мизгелгә булса да күтәрергә теләп, хокүмәт белән бергә Мордовия күләмендә хормәтлибез. Гадәттәгечә, Олкәннәр айлыгында Темников районы Митрял авыл китапханәчесе Ялышева Венера Рәшит кызы белән авыл клубы модире Утешева Зәйнәб Шәмил кызы картларга (1нче биттә уртада утыручы Алия Амин кызы Урусова) һәм уллары СВОда булган ата-аналарга баллы бүләкләр тапшырдылар. Ә 10 октябрь конне Митрялы мәдәният йортында олыларны жыеп концерт оештырды







